**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.09.2017 Балык Бистәсе штп. № 197пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль тәэмин итү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына мохтаҗлык критерийларын адреслау һәм куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль законнар нормаларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында» 2014 елның 16 гыйнварындагы 06пи номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 июлендәге 128пи номерлы, 2017 елның 29 мартындагы 57п номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2.1, 2.2 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.1.Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - СТБДМС) куллану юлы белән һәм СТБДМС операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

2.2.Әлеге карарда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, СТБДМС операторы

тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, СТБДМСны куллану юлы белән алынырга мөмкин.».

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф өлкәсендә бөтенроссия олимпиадаларының региональ этабы җиңүчеләре һәм призерлары өчен «Признание» премиясе турында» гы 2014 елның 28 апрелендәге №70пи карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 3.1, 3.2 пунктлар белән тулыландырырга: «3.1.Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - СТБДМС) куллану юлы белән һәм СТБДМС операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

3.2.Әлеге карарда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, СТБДМС операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, СТБДМС ны куллану юлы белән алынырга мөмкин.».

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында» гы 2017 елның 16 гыйнварындагы 07пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 6.1, 6.2 пунктларын өстәргә:

«6.1.Әлеге карар нигезендә гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирә торган органнар күрсәтелгән гарантияләрне, социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - СТБДМС) куллану юлы белән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба- СТБДМС) куллану юлы белән бирү турында мәгълүмат бирүне, СТБДМС операторы билгеләгән форматларга туры китереп тәэмин итәләр.

6.2.Гражданнарның әлеге карарда күрсәтелгән категорияләренә бирелгән (бирелә торган) гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар турында мәгълүмат СТБДМСны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә куллану юлы белән һәм СТБДМС операторы билгеләгән форматларга туры китереп алынырга мөмкин.».

4.Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

6.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарның күчермәсен Россия Пенсия фондының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы идарәсенә җибәрергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин